**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОШТАУЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2022 ел, 2 июнь №77

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Су Кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 маендагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 июлендәге 177 номерлы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлегенең генераль планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 таблицаның 1 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«туфракның уңдырышлылыгын арттыру максатларында агып төшүче сулардан файдалану;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Коштаулы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Коштаулы авыл җирлеге**
**Башлыгы** **Х. Ф. Сабиров**